Республика Татарстан
Глава Тураевского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423647, село Тураево,
ул. Центральная. 11А

Татарстан Республикасы
Менделеев
муниципаль районы
Турай авыл жирлеге
башкарма комитеты
423647, Турай авылы,
Узәк урам, 11А

Тел./факс 2-73-31

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.11.2024 № 5

Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,
КАРАР БИРӘМ:
1.2024 елның 14 ноябре 14.00 сәгатьтә Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Татар Әхтиялы авылы, Үзәк урам 9 Б йорты адресы буенча урнашкан иҗтимагый үзәк бинасын билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

“2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Татар Әхтиялы авылындагы чишмәне төзекләндерү);
2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Әхтиялы торак пунктының Ключевая урамындагы юл өслегенә вак таш белән чокырларны ремонтлау; Татар Әхтиялы торак пунктындагы юл өслеген вак таштан соң тигезләү ( эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).)

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татар Әхтиялы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Турай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б.Куляшова